**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«16» 02 2022 ел Яр Чаллы ш. № 415

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дини оешмаларга дәүләт һәм муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, дини оешмаларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль милегендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыруны хокукый җайга салуны камилләштерү максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия төзергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 февралендәге 415 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия тарафыннан аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларга муниципаль милектәге мөлкәтне тапшыру турында карарлар кабул итү өчен нигез булып тора.

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты.

2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә дини оешмаларның муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында гаризаларын караганда барлыкка килә торган фикер каршылыгын җайга салу.

2.2. Дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә яисә дини оешманың гаризасын карауга бәйле рәвештә вәкаләтле органның гамәлләренә (гамәл кылмавына) физик һәм юридик затларның аларның хокукларын һәм (яки) законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гаризаларын карау.

## 3. Комиссиянең төп функцияләре

3.1. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

3.1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат сорый.

3.1.2. Үз утырышларында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары, дини белем, культурология, хокук өлкәләрендә һәм башка өлкәләрдә комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча оешмалар һәм белгечләрне тыңлый.

3.1.3. Үз компетенцисе чикләрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру яки тапшырудан баш тарту турында вәкаләтле органга рекомендация белән нигезләнгән карар кабул итә.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы:

4.1.1. Комиссия эшендә катнашу өчен, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары, дини белем, культурология, хокук өлкәләрендә һәм башка өлкәләрдә оешмалар һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

4.1.2. Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләрне карау өчен эшче төркемнәр булдырырга.

## 5. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

5.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән раслана.

5.2. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

5.3. Комиссия эшчәнлегенә комиссия рәисе җитәкчелек итә.

5.4. Комиссия утырышлары әлеге Нигезләмә нигезендә комиссиянең карарын таләп итә торган мәсьәләләр барлыкка килгән саен уздырыла. Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.5. Комиссия утырышларын чакыру, үткәрү һәм ул кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тоту комиссия рәисенә йөкләнә. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бирергә хокуклы.

5.6. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа аның рәисе һәм комиссия секретаре кул куя.

Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия әгъзаларының кабул ителгән карар белән килешмәгән аерым фикере комиссия карарына кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә.

5.7. Комиссия карары, шулай ук әлеге карар белән килешми торган комиссия әгъзаларының аерым фикере 7 көн эчендә интернет челтәрендә урнаштыру өчен, вәкаләтле органга җибәрелә.